| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Лешев-Тамакского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Ләшәү Тамак авыл җирлеге<br>советы |

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 29 декабрь

№ 23

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә класс чинын бирү турында тәкъдим кертелгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча, органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазифаи затына кабул ителергә тиеш.»;

2) 4.6.1 пунктында икенче җөмләне алып ташларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы рәисе

И.З.Хабибуллин